СОВЕТ ЛЕНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЛЕНИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

ул. 40 лет Победы д. 32,
с. Ленино,423181

Җиңүнең 40еллыгы урамы, 32,
Ленино авылы, 423181

тел.: (8-4348) 3-44-16, факс: (8-4348) 3-44-10; Lenin.nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль
районы Ленино авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2025 елның 30 нчы декабре № 4-12

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 7.11.2014 № 35-70 карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2025 елның 28 ноябрендәге 425-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 7.11.2014 № 35-70 карарына (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге Советының 11.09.2015 № 46-97, 23.10.2015 № 3-10, 14.11.2018 № 53-102, 21.09.2019 № 63-124; 26.03.2021 № 9-22;) номерлы карарлары редакциясендә) (алга таба – Карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. карарның 2 пунктындагы 4 пунктчасында «300 миллион сум» сүзләреннән соң: « проектлана торган билгеләнеше күпфатирлы йорт булган төзелеп бетмәгән объектлардан тыш» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» нда: https://pravo.tatarstan.ru «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге Советының җирдән файдалану, торак-коммуналь хуҗалык һәм территорияне төзекләндерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Ленино авыл җирлеге башлыгы С. Ю. Питеркина